МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.05.2025 Казан ш. № 274-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 07.11.2024 № 655-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Федераль законнардагы үзгәрешләргә бәйле боерам:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 07.11.2024 № 655-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган тәкъдим ителгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары А.И. Галиевка йөкләргә.

**Министр** **А.Р.Кадыйров**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
19.05.2025 № 274-пр
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 07.11.2024 № 655-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган тәкъдим ителгән үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.6.2.1 пунктта:

тугызынчы абзацта «11, 12» цифрларын «8, 9» цифрлары белән алмаштырырга;

унынчы абзацта «13, 14» цифрларын «10, 11» цифрлары белән алмаштырырга;

2.6.2.2 пунктның дүртенче абзацында «15» цифрын «12» цифры белән алмаштырырга;

2.6.2.3 пунктның дүртенче абзацында «16» цифрын «13» цифры белән алмаштырырга;

2.6.6.1 пунктның алтынчы абзацында «13, 14» цифрларын «10, 11» цифрлары белән алмаштырырга;

2.6.6.2 пунктның дүртенче абзацында «15» цифрын «12» цифры белән алмаштырырга;

2.6.6.3 пунктның сигезенче абзацында «16» цифрын «13» цифры белән алмаштырырга;

3 бүлектә:

3.6.2.2 пунктта унөченче абзацны көчен югалткан дип танырга;

3.6.3 пунктта:

дүртенче абзацта «Бүлек белгече әзерләгән» сүзләрен «Гариза бирүче таләбе буенча документларны кабул итүдән баш тарту язмача әзерләнә.» сүзләре белән алмаштырырга;

җиденче абзацны «телдән» сүзеннән соң «(язмача)» сүзе белән тулыландырырга;

3.9.9 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9.9. Бүлек белгече күрсәтелгән проектлар буенча кимчелекләр бәян ителгән хокук идарәсе бәяләмәсен алган очракта булган кимчелекләрне төзәтә һәм җиренә җиткереп эшләнгән җир кишәрлеген бирү турында карар проектын һәм сату-алу шартнамәсе проектын, яки аренда шартнамәсе проектын, яки түләүсез файдалану шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын килештерү өчен кабаттан хокук идарәсе башлыгына юллый.»;

Административ регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга биргәндә дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап гариза бирүчеләр

Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләре түбәндәгеләргә түләүсез файдалануга бирелә ала:

1) дәүләти һәм муниципаль учреждениеләргә (бюджет, казна, автоном) бер елга кадәр срок белән;

2) казна предприятиеләренә бер елга кадәр срок белән;

3) Россия Федерациясенең үз вәкаләтләрен башкаруны туктаткан президентларының тарихи мирас үзәкләренә, бер елга кадәр срок белән;

4) Россия банкына бер елга кадәр срок белән;

5) дини оешмаларга дини яисә хәйрия билгеләнешендәге биналарны, корылмаларны урнаштыру өчен, ун елга кадәр срок белән;

6) әгәр ул җирдә түләүсез файдалану хокукында аларга караган биналар, корылмалар урнашкан булса, дини оешмаларга – күрсәтелгән бинага, корылмага хокук срогы беткәнчегә кадәр;

7) дини оешмаларга кырык тугыз елга кадәр срокка, күрсәтелгән җир кишәрлекләрендә милек хокукындагы дини яисә хәйрия билгеләнешендәге биналар, корылмалар урнашу шарты белән, әгәр күрсәтелгән җир кишәрлекләре

әйләнештә чикләнгән булса һәм (яисә) әлеге дини оешмаларга милеккә бирелә алмаса;

8) коммерциячел булмаган оешмаларга, күрсәтелгән җир кишәрлекләрендә түләүсез файдалану хокукындагы һәм дәүләт яисә муниципаль милектәге биналар, корылмалар урнашу шарты белән, мондый биналарга, корылмаларга хокуклар туктатылганчы;

9) "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эш, хезмәт күрсәтү өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп, тулысынча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы хисабына күчемсез милек объектлары төзелеше яисә реконструкция буенча гражданлык-хокук шартнамәсе төзелгән затларга, шартнамә башкарылу срогына;

10) тулысынча федераль бюджеттан субсидия буларак алынган акчаларга әлеге җир кишәрлекләрендә капиталь төзелеш объектларын төзү һәм (яки) реконструкцияләү өчен коммерциячел булмаган оешмаларга, төзелеш һәм (яки) капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү срогына;

11) Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару яки крестьян (фермер) хуҗалыклары эшчәнлеге өчен муниципаль берәмлекләрдә җир кишәрлеге бирелгән гражданнарга, алты елдан да артмаган срокка;

12) Татарстан Республикасы законнары белән белгеләнгән шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмчел хуҗалык шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен муниципаль берәмлекләрдә җир кишәрлеге бирелгән һәм әлеге муниципаль берәмлекләрдә Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән белгечлекләр буенча эшләүче гражданнарга, алты елдан да артмаган срокка;

13) әлеге җир кишәрлегендә хезмәт торагы булган йорт урнашкан булса, хезмәт торагы итеп йорт бирелгән гражданнарга, әлеге торак йорт белән файдалану срогында;

14) коммерциячел булмаган яшелчәчелек яисә бакчачылык ширкәтләренә - биш елдан да артык булмаган срокка;

15) торак төзелеше максатыннан гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешмаларга – федераль законнарда каралган очракларда һәм срокларда;

16) «Дәүләт оборона заказы турында» 2012 елның 29 декабрендәге № 275-ФЗ Федераль законга, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эш, хезмәт күрсәтү өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законга нигезләнеп, илнең оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү өчен тулысынча федераль бюджет хисабына эшләр башкаруга, хезмәт күрсәтүгә дәүләт контракты төзелгән затларга, әгәр дә аларга

бу эшләрне башкару һәм хезмәтләрне күрсәтү өчен җир кишәрлеге бирү зарурлыгы булса, күрсәтелгән контрактны башкару срогында;

17) Федераль законда, Россия Федерациясе Президенты Указында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актында, Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән аерым категориядәге гражданнарны торак урыннары белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Законында каралган һәм Татарстан Республикасы тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешмаларга әлеге төзелешне гамәлгә ашыру чорына күрсәтелгән торак урыннарын төзү максатларында;

18) Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлегеннән түләүсез файдалану хокукы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген тартып алуга бәйле рәвештә туктатылган затларга, тартып алынган җир кишәрлеге урынына тартып алынган җир кишәрлегенә түләүсез файдалану хокукы барлыкка килү нигезенә бәйле рәвештә законнарда билгеләнгән срокка;

19) «Торак төзелеше үсешенә, туристлык инфраструктурасы объектлары булдыруга һәм территориянең башка үсешенә ярдәм турында» 2008 елның 24 июлендәге № 161-ФЗ Федераль законда каралган затларга шул очракларда һәм тәртиптә;

20) «Почта России» федераль дәүләт унитар предприятиесен реорганизацияләү үзенчәлекләре, «Почта России» акционерлык җәмгыятенең эшчәнлек нигезләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 29 июнендәге № 171-ФЗ Федераль закон нигезендә «Почта России» акционерлык җәмгыятенә;

21) “Төзелеш тармагында бердәнбер заказ бирүче” гаммәви-хокукый компаниясенә - агымдагы елда һәм план периодында эшчәнлек программасына кертелгән инженерлык тикшеренүләрен, архитектура-төзелеш проектлауларын, реконструкцияләр, капиталь ремонт, капиталь төзелеш объектларын сүтү эшләрен тәэмин итү өчен, “Төзелеш тармагында бердәнбер заказ бирүче” гаммәви-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 22 декабрендәге № 435-ФЗ Федераль законы нигезендә.

22) «Территорияләрнең үсеше фонды» гаммәви-хокукый компаниясенә «Территорияләрнең үсеше фонды» гаммәви-хокукый компаниясе һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 29 июль, 2017 ел, № 218-ФЗ Федераль законда каралган функцияләрне һәм вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен, «Түләргә сәләтсезлек турында (банкротлык)» 2002 ел, 26 октябрь, № 127-ФЗ Федераль законда каралган шартларда күрсәтелгән гаммәви-хокукый компаниягә тапшырылган (тапшырылырга мөмкин булган) җир кишәрлегендә төзелеп бетмәгән объектларны (капиталь төзелеш

объектларын төзү) төзеп бетерү Россия Федерациясенең җир һәзм башка законнарында билгеләнгән чикләүләр аркасында мөмкин булмаган очракта, андый чикләүләр Россия Федерациясе Шәһәр төзү кодексына таянып төзелеш өчен рөхсәт бирү вәкаләтләре булган башкарма хакимиятнең федераль органы, Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органы, җирле хакимият органы тарафыннан расланган булса;

23) «Роскадастр» гаммәви-хокукый компаниясенә, «Роскадастр» гаммәви-хокукый компаниясе турында» федераль законына таянып таратылган федераль дәүләт учреждениеләренә даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирелгән җир кишәрлекләренә мөнәсәбәтле.»;

Административ регламентның 5 нче кушымтасында 13 подпунктында «басылган һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.».